**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**
**2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бохарай авыл җирлегенең Бохарай торак пунктында**

2024 елның 12 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлегендә халык җыены, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлегендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Бохарай авыл җирлеге Бохарай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мәктәп урамы һәм Су арты урамнары буенча торак пункт эчендәге юлны ремонтлау).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бохарай авыл җирлеге башлыгы Е.В. Груздева